СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2020 г. Заинск № 527

**Зәй муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары турында**

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 01 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 03 апрелендәге 439 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору буенча кушымта итеп бирелгән шартларны расларга.
2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Советының
03.06.2020 ел
527 номерлы карары белән
расланган.

**Зәй муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары**

1. Күчемсез мөлкәттән файдаланган өчен 2020 елда каралган аренда түләвен кичектерүнең әлеге шартлары 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Федераль законның 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки аңа югары әзерлек режимын кертү турында карар кабул ителгәнче, Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр булган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары (алга таба - аренда шартнамәсе, кичектерү) белән расланган яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә вәзгыятьнең начараюы шартларында иң күп зыян күрүче арендаторлар белән төзелгән күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләренә карата кулланыла.

2. Кичектерү, торак биналардан тыш, күчемсез милеккә карата бирелә.

3. Кичектерү 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки аңа югары әзерлек режимы кертелгән көннән соң түбәндәге шартларда бирелә:

а) аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да алдарак түгел һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкыр, аренда килешүе буенча айлык аренда түләве күләменең яртысыннан да артмаган бертигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

б) кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки аңа югары әзерлек режимының гамәлдә булу срогына тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә һәм 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки аңа югары әзерлек режимы туктатылган көннән алып, тиешле чорда аренда түләвенең 50 проценты күләмендә бирелә;

в) кичектереп торылуга бәйле рәвештә аренда түләвен (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яисә башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

г) кичектерү бирелүгә бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне арендага бирүче тарафыннан билгеләү рөхсәт ителми;

д) кичектерү бирелә торган аренда түләве күләме яклар килешүе буенча киметелергә мөмкин;

е) әгәр аренда шартнамәсендә арендатордан коммуналь хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган өчен түләүләрне һәм (яисә) арендага бирелә торган мөлкәтне тотуга чыгымнарны аренда түләвенә кертү каралган булса, аренда түләвенең күрсәтелгән өлеше буенча кичектерү бирелми, әгәр Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яисә аңа югары үзерлек режимы гамәлдә булган чорда арендага бирүче мондый хезмәтләр өчен түләүдән һәм (яисә) мондый чыгымнар тотудан азат ителсә.

4. 3 пунктта каралган кичектерү шартлары мондый килешү төзү датасына бәйсез рәвештә кичектерү турында аренда шартнамәсенә өстәмә килешүләргә карата кулланыла.